ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**КАРАРЫ** **КАРАР**

№ 38 . 14.02.2023

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 01 июлендәге 213 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга өстәмә компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» сүзләрен «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2)түләү билгеләү турында гариза бирелгән айдан алдагы айның соңгы 12 календарь аендагы гаилә әгъзаларының керемнәре турында документлар;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булганда компенсация билгеләү Россия Федерациясе Пенсия фондында түләүләрне билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан соңгы 12 календарь айда булган гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр нигезендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatrstan.ru) игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

**Җитәкче** **А.А. Тугушев**